Зур Кукмара авыл җирлеге Советы

КАРАР

2020 елның 15 июне №9

Дүртенче чакырылыш Зур Кукмара авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын билгеләү турында.

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше, 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының12 статьясы нигезендә Зур Кукмара авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Дүртенче чакырылыш Зур Кукмара авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча, «Хезмәт даны» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Кукмара муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://kukmor.tatarstan.ru урнаштырырга.

Зур Кукмара авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Хәнәфиев